| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

“08” февраль 2024 ел Борындык ав. № 70

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 19 октябрендәге 62 номерлы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 19 октябрендәге 62 номерлы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлеге Советы карарына (алга таба текст буенча – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 3.7.1 пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- Нигезләмәнең 3.11 пункты үз көчен югалткан дип танырга;
- Нигезләмәнең 3.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.13 муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгының барлык кирәкле документлары булган классны чин бирү турындагы күрсәтмә кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Борындык авыл җирлеге башлыгы А.Р.Гайнетдинов